**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№523**
**04.02.2019**

Яр Чаллы шәһәренең «Тантана сарае» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль Законның 17 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 маддәсендәге 2 пунктның 5 пунктчасы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезнамәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе хакындагы нигезнамә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2019-2023 елларга Яр Чаллы шәһәренең «Тантана сарае» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 4 февралендәге
523 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Тантана сарае»
муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган
хезмәтләргә тарифлар

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Хезмәтнең бәясе |
|---|---|---|---|
| 1. | Тантаналы церемония оештыру һәм үткәрү | сәгать | 2 750,00 |
| | Кунакларны озатып йөрү | сәгать | 1 200,00 |
| | Фуршет хезмәте күрсәтү | сәгать | 1 150,00 |
| | Тантаналы церемония өчен килешүләр рәсмиләштерү | сәгать | 400,00 |
| 2. | Музыка белән алып бару (камера ансамбле) | церемония | 1 100,00 |
| 3. | Музыка белән алып бару (соло) | церемония | 650,00 |
| 4. | Музыка белән алып бару (вокал) | церемония | 650,00 |
| 5. | Индивидуаль сценарий әзерләү | церемония | 525,00 |
| 6. | Фотога төшерү | церемония | 1 000,00 |
| 7. | Видеога төшерү | церемония | 1 000,00 |
| 8. | Документларның күчермәсен ясау | бит | 5,00 |
| 9. | Гаиләләргә барып церемония үткәрү (транспорт чыгымнарыннан тыш) | сәгать | 4 000,00 |
| 10. | Күгәрченнәр очыру йоласы оештыру һәм үткәрү | церемония | 650,00 |
| 11. | Роза таҗларыннан салют | церемония | 200,00 |
| 12. | Исемле (гаилә) диплом тапшыру церемониясе | церемония | 400,00 |
| 13. | Чит оешмаларның чараларын (оешмаларның, фирмаларның һәм аларның продукциясенең күргәзмә-демонстрацияләре, презентацияләре, күргәзмә-сатулар, баллар һ.б.) әзерләү һәм үткәрү | сәгать | 1 600,00 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова